БАЛТАСИНСКИЙ
РАЙОННЫЙ СОВЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13 декабрь 2024 ел № 294

**«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Муниципаль берәмлекләрнең уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Законы, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районa Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар бирде:**

1. «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1) 6 статьяның 1 пунктындагы 13 пунктчасында** «шул исәптән Район территориясендә планлаштырылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекне әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарга ярашлы рәвештә иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү» сүзләрен өстәргә;

**2) 6 статьяның 1 пунктының 28 пунктчасында** «Район территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларны булдыру, үстерү һәм саклауны тәэмин итү, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;

**3) 6 статьяның 1 пунктындагы 34 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«34) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләр хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

**4) 6 статьяның 1 пунктындагы 35 пунктчасында** «, шулай ук су объектларыннан рекреацион максатлар өчен файдалану кагыйдәләре» сүзләрен өстәргә;

**5) 8 статьяның 3 пунктына** «торак законнары нигезендә җирле үзидарәнең» сүзләрен өстәргә;

**6) 8 статьяга түбәндәге эчтәлекле 26 пункт өстәргә:**

«26) авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары) эшчәнлеген булдыруны һәм тәэмин итүне, автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм авыл җирлекләренең торак пунктлары чикләрендә юл хуҗалыгында муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, юл хәрәкәтен оештыру, шулай ук автомобиль юлларыннан файдалану өлкәсендә башка вәкаләтләрне башкару һәм юл эшчәнлеген Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашыру;»;

**7) 8 статьяга түбәндәге эчтәлекле 27 пункт өстәргә:**

«27) авыл җирлекләре чикләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтүдә һәм алардан килгән зыянны бетерүдә катнашу;»;

**8) 8 статьяга түбәндәге эчтәлекле 28 пункт өстәргә:**

«28) әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклау һәм авыл җирлекләре милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата мондый зыянны бетерүне оештыру.»;

**9) 26 статьяның 7 пунктына түбәндәге эчтәлекле 10.1 пунктча өстәргә:**

«10.1) аларга чит ил агенты статусы алу;»;

**10) 29 статьяның 27 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«27) муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яисә) челтәр басмасы учреждениесе;»;

**11) 43 статьяның 1 пунктындагы 3 пунктчасының дүртенче абзацында** «шул исәптән район территориясендә планлаштырыла торган хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру» сүзләрен өстәргә;

**12) 43 статьяның 1 пунктындагы 3 пунктчасының бишенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;**

**13) 43 статьяның 1 пунктындагы 3 пунктчасының алтынчы абзацында** «Район территориясендә дәвалау-савыктыру урыннарын һәм җирле әһәмияттәге курортларны саклауны булдыра, гамәлгә ашыра,» сүзләрен төшереп калдырырга;

**14) 43 статьяның 1 пунктындагы 3 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле унберенче абзац өстәргә:**

«- әйләнә-тирә мохиткә тупланган зыян объектларын ачыклауны һәм Район милкендәге җир кишәрлекләре чикләрендә урнашкан территорияләргә карата мондый зыянны бетерүне оештыруны гамәлгә ашыра. »;

**15) 43 статьяның 1 пунктындагы 5 пунктчасының унынчы абзацында** «(волонтерлыкка)» сүзләрен өстәргә;

**16) 43 статьяның 1 пунктындагы 5 пунктчасының унберенче абзацында** «физик культура» сүзләреннән соң «, мәктәп спорты» сүзләрен өстәргә;

**17) 43 статьяның 1 пунктындагы 5 пунктчасының унөченче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;**

**18) 43 статьяның 1 пунктындагы 5 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле уналтынчы абзац өстәргә:**

« Район милкендә булган мәдәни мирас объектларын (тарих һәм мәдәният ядкарьләрен) саклап калуны, алардан файдалануны һәм аларны

популярлаштыруны, район территориясендәге җирле (муниципаль) әһәмияттәге мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәният ядкарьләрен) саклауны тәэмин итә.»;

**19) 43 статьяның 1 пунктындагы 6 пунктчасының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча җирлекара характердагы чараларны оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

**20) 43 статьяның 1 пунктындагы 8 пунктчасының алтынчы абзацында** «, шулай ук су объектларыннан рекреацион максатлар өчен файдалану кагыйдәләре» сүзләрен өстәргә;

**21) 58 статьяның 3 пунктына түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:**

«12) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15.2 статьясында каралган анкетада яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) булган белешмәләрнең аңа мәгълүм булган үзгәрешләр турында язма рәвештә хәбәр итәргә, яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары буенча үзгәреш кичергән белешмәләрдән тыш.»;

**22) 78 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«78 статья. Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе

1. Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагыла торган муниципаль норматив хокукый актлар, гамәлгә куючысы Район булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне игълан итү дигәндә түбәндәгеләр аңлашыла:

1) муниципаль хокукый актны рәсми бастырып чыгару;

2) Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан мәгълүмати стендларда муниципаль хокукый актны чикләнмәгән затлар даирәсе өчен һәркем файдалана алырлык итеп урнаштыру;

3) районның рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (https://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру.

3. Муниципаль хокукый актны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми бастырып чыгару дип аның тулы текстының беренче тапкыр басылып чыгуы санала (https://pravo.tatarstan.ru; Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ № ФС77-60244 номерлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык).

4. «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү турында» 2009 елның 9 февралендәге 8-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданнарның Татарстан

Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталыннан файдалана алуын тәэмин итү, алардан чикләнмәгән даирә кешеләре куллана алсын өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташтыру пунктлары өстәмә техник чаралар кулланмыйча түбәндәге адреслар буенча урнашкан: Балтач шәһәр тибындагы бистә, Ленин ур., 45 йорт (Балтач үзәк авылара китапханә бинасы), Балтач шәһәр тибындагы бистә, В.Булатов ур., 24/2 й.(Татарстан Республикасында күпфункцияле үзәкнең Балтач филиалы бинасы).

5. Федераль закон белән таратылуы чикләнгән белешмәләре булган муниципаль хокукый актлар яисә аларның аерым нигезләмәләре халыкка җиткерелергә тиеш түгел.

Әлеге пунктның беренче абзацы нигезендә халыкка җиткерелмәгән муниципаль хокукый актлар яисә аларның аерым нигезләмәләре мәҗбүри рәвештә җирле үзидарә органнарына, аларның вазыйфаи затларына, депутатларга, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларына, шулай ук әлеге хокукый актларның гамәлдә булуы кагыла торган гражданнарга һәм оешмаларга җиткерелә.

6. Җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган муниципаль норматив хокукый актлар, килешүләр имза салынган көннән алып 10 көн эчендә халыкка җиткерелергә тиеш, рәсми игълан ителгән көннән соң 7 көн узгач үз көченә керәләр, әгәр гамәлдәге законнар белән һәм (яисә) норматив хокукый актларның үзләре, килешүләр нигезендә үз көчләренә керүнең башка тәртибе билгеләнмәгән булса.

Җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган муниципаль норматив хокукый актлар, килешүләр әлеге статьяның 2 пунктының 2 һәм 3 бүлекләрендә аларны чыгарган Район җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары карары белән каралган ысуллар белән халыкка җиткерелергә мөмкин.

7. Район Советының салымнар һәм җыемнар турында муниципаль норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә үз көченә керә.

8. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар әлеге актларны кабул иткән Районның җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарәнең вазыйфаи затларының хәл итүе буенча халыкка җиткерелергә мөмкин, әгәр алар гамәлдәге законнар нигезендә төзелсә һәм (яисә) хокукый актларның кертүнең башка тәртибе билгеләнмәгән булса, аларга имза салган көннән үз көченә керәләр.

9. «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә тиешле сайтларның домен исемнәре һәм аларны массакүләм мәгълүмат чаралары буларак теркәү турындагы мәгълүматлар күрсәтелгән вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге, аларда муниципаль хокукый актлар, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр игълан ителә, район башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән гомуми мәгълүматка кадәр җиткерелә.».

**23) Уставның 81 статьясына түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:**

«4. Районның Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы муниципаль милектәге объектларны түләүсез биләүгә һәм файдалануга тапшыруны гамәлгә ашыра, Россия Федерациясенең электр энергетикасы турындагы законнарында

билгеләнгән очракларда, тәртиптә һәм шартларда, система барлыкка китерүче электр челтәре хуҗалыгына яисә Татарстан Республикасы чикләрендә эш итүче территориаль челтәр оешмасына.».

2. Законнарда билгеләнгән тәртиптә әлеге карарны дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Дәүләт теркәвенә алынганнан соң әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы башлыгы урынбасары Н.Н. Сабирҗановка йөкләргә.

Балтач муниципаль районы башлыгы,
Балтач район Советы рәисе Р.Р.Нотфуллин